ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БОЛЬШЕМЕМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Советская, д.62, с. Татарское Бурнашево,
422579

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ОЛЫ МЕМИ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Совет ур., 62 нче йорт, Татар Борнашы авылы,

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

с. Большие Меми

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48

16.12.2019 | 51

Югары Ослан муниципаль районының Олы Меми авыл җирлегендә урнашкан су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу объектларын тикшерү һәм категорияләү буенча комиссия төзү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 23 декабрендәге 1467нче номерлы «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу объектларының террорчылыкка каршы яклануына карата таләпләрне, су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу объектларының куркынычсызлык паспортының формасын раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» карары белән расланган су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу объектларының террорчылыкка каршы яклануына карата таләпләр нигезендә карар бирәм:

1. Югары Ослан муниципаль районы Олы Меми авыл җирлеге территориясендә урнашкан су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу объектларын карау һәм категорияләү буенча түбәндәге составта комиссия төзергә:

| Номер | ФИО | Вазифа |
|---|---|---|
| Комиссия рәисе | | |
| 1 | Фомина Галина Александровна | Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Олы Меми авыл җирлеге башлыгы |
| Комиссия әгъзалары | | |
| 2 | Мартынов Дмитрий Алевтинович | Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча Зеленодольский шәһәрендәге идарәсе |
| 3 | Гайнуллин Айдар Дамирович | «Россия УВО ВНГ Татарстан Республикасы буенча» ПЦО ОВО Зеленодольский районы буенча ФГКУфилиалы начальнигы |
| 4 | Садыйков Әнәс Дамирович | Татарстан Республикасы буенча РФ ГТХМ Баш идарәсенең Югары Ослан муниципаль районы буенча күзәтчелек эшчәнлеге бүлеге башлыгы |

2. Комиссия үз эше барышында:
а) су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу объектында террор актлары кылу куркынычы дәрәҗәсен билгели;

б) су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу объектының конструктив һәм техник характеристикаларын, аның эшчәнлеген оештыруны, су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу объектының куркынычсыз эшләвен тәэмин итү буенча гамәлдәге чараларны өйрәнә;
в) инфраструктура һәм яшәү тәэмин итү өчен су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу объектының әһәмиятен билгели;
г) су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу объектының критик элементларын ачыклый;
д) су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу объектында террор актлары кылуның ихтимал нәтиҗәләрен билгели;
е) су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу объектының категориясен билгели яки элек бирелгән категорияне раслый (үзгәртә) ;
ж) су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу объектын аның категориясе нигезендә террорчылыктан сакланганлыгы торышына тикшерү үткәрә;
з) аның категориясен исәпкә алып, су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу объектының террорчылыкка каршы яклануын тәэмин итү чараларын, шулай ук әлеге чараларны гамәлгә ашыру вакытын, планлаштырылган эшләр һәм финанслау чыганакларын исәпкә алып, билгели.

3. Комиссия эшенең нәтиҗәләре кушымта нигезендә объектны тикшерү һәм категорияләү акты белән рәсмиләштерелә.

Югары Ослан муниципаль районы
Олы Меми авылы авыл җирлеге Г. А. Фомина

объектны (су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу) тикшерү һәм категорияләү

АКТы

Комиссия башлану датасы: __________________
Комиссия эше тәмамлану датасы: ______________________
Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу объектларының террорчылыкка каршы якланyына таләпләрне, су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу объектларының куркынычсызлык паспортының формасын раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 23 декабрендәге 1467нче номерлы карары белән расланган су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу объектларының террорчылыкка каршы якланyына карата таләпләр, № _________ боерык (карар) нигезендә «_____»___________________2019 ел
Директор ...« ... » ........., составтагы объектны тикшерү һәм категорияләү комиссиясе:
Комиссия рәисе:
Комиссия әгъзалары:

1. Фомина Галина Александровна
2. Мартынов Дмитрий Алевтинович
3. Гайнуллин Айдар Дамирович
4. Садыйков Әнәс Дамирович

Су белән тәэмин итү объектын тикшерү һәм категорияләү үткәрде.........................................
Эксплуатацияләүче оешма: ………………………………………………

Комиссия эше барышында түбәндәгеләр ачыкланды:
1. Объект турындагы документларны өйрәнү, белгечләрне сораштыру объектын тикшерү һәм алынган мәгълүматларны анализлау нәтиҗәләре буенча әлеге объектның категория критерийларының түбәндәге күрсәткечләре билгеләнде:

| | | |
|---|---|---|
| 1 | Объект йогынтысы зонасында яшәүче кешеләр саны | Мең кеше. |
| 2 | Россия Федерациясенең критик мөһим һәм потенциаль куркыныч объектлары исемлегенә кертелгән оешмалар тарафыннан су белән тәэмин итү хезмәтләре күрсәтү | |

| | | |
|---|---|---|
| 3 | Объектка һәм аның даирәсендә урнашкан инфраструктурага, шулай ук әйләнә-тирә табигать мохитенә китерергә мөмкин матди зыян | Млн. сум |
| 4 | Объектта террорчылык акты янау дәрәҗәсе | |
| 5 | Объектта куркыныч матдәләр куллану | |

Югарыда күрсәтелгән категория критерийларының санын бәяләү нәтиҗәләре буенча, су белән тәэмин итү объектларының категорияләре нигезендә билгеле бер категориягә кертергә мөмкинлек бирә торган билгеләре юк.

Комиссия рәисе: Галина Александровна Фомина

Комиссия әгъзалары: Дмитрий Алевтинович Мартынов
Айдар Дамирович Гайнуллин
Әнәс Дамирович Садыйков